Приложение 2

**“Балачак жыры” II бәйгесен үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Әлеге Нигезләмә татар телендә балалар өчен җыр иҗат итүчеләрнең «Балачак җыры» («Песня детства») II бәйгесенең (алга таба – Бәйге) максат һәм бурычларын, үткәрү вакытын һәм тәртибен, гариза юллау регламентын, музыкаль әсәрләрне сайлап алу кагыйдәләрен, шулай ук Бәйге җиңүчеләрен бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Бәйгене “Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе” АҖ нең «ШАЯН ТВ» телеканалы (алга таба - Оештыручы) үткәрә. Бәйгенең максаты – татар телендә балалар өчен җыр иҗат итүче талантлы композитор һәм шагыйрьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү, татар телендә язылган балалар җырларын популярлаштыру.

1.3. Оештыручының юридик адресы: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ш. Усманов ур., 9 йорт.

## 2. БӘЙГЕНЕҢ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Татар телендә язылган балалар җыры репертуарын баету.

2.2. Татар телендә язылган балалар җырларын пропагандалау һәм татар җырларын җәмгыятькә таныту.

## 3. БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫЛАРГА ТАЛӘПЛӘР

3.1. Бәйгедә композитор белән шагыйрь бер Катнашучы булып санала. Шагыйрь белән композитор бергә юллаган гариза бер катнашучыдан (алга таба – Катнашучы) юлланган гариза буларак кабул ителә.

Оештыручы карары буенча бер үк катнашучыга композитор да, шагыйрь дә буларак катнашырга рөхсәт ителергә мөмкин.

3.2. Бәйгедә 18 яше тулган теләсә кайсы физик зат катнаша ала.

3.3. Бәйгедә “Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе” хезмәткәрләренә һәм аларның туганнарына катнашу рөхсәт ителми.

3.4. Бәйгедә катнашу бушлай. Оештыру өчен түләү каралмаган.

3.5. Бәйгедә Катнашучы 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 152-ФЗ номерлы “Шәхси мәгълүматлар турында”гы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларын кулланырга ризалык бирә.

3.6. Бәйгедә катнашып, Катнашучы үз әсәрен Нигезләмә максатларында алга таба да вакытын һәм куллану даирәсен чикләмичә кулланырга ризалык бирә.

3.7. Бәйгедә катнашу автомат рәвештә Катнашучының бәйге шартлары белән таныш булуын һәм алар белән тулысынча риза булуын күз алдында тота. Әлеге Нигезләмә Бәйгедә катнашучыларның барысы өчен дә расланган һәм мәҗбүри булып тора.

3.8. Бәйгедә катнашу Катнашучыларның шәхси мәгълүматларын Бәйге үткәрелгән вакытта автомат рәвештә куллануны, шулай ук Бәйге тәмамланганнан соң да мәгълүмати һәм реклама максатларында куллануга ризалык бирүләрен күз алдында тота. Катнашучылар барлык массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, шул исәптән «ШАЯН ТВ» телеканалының YouTube каналында бәйгедә катнашу турында интервью бирергә, шулай ук видео һәм график материаллар әзерләүдә нинди дә булса бүләкләрсез катнашырга ризалаша.

## 4. БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ ҺӘМ АҢА ЙОМГАК ЯСАУ ТӘРТИБЕ.

4.1. Бәйге 2021 елның 1 февраленнән 2021 елның 01 июненә кадәр ( 01 июньне дә кертеп) үткәрелә.

4.2. Бәйгегә килгән эшләрне даими рәвештә ике составта эшләүче жюри бәяләячәк: профессиональ жюри (югары һөнәри белемле) һәм балалардан торган жюри (җыр бәйгеләре лауреатлары, балалар телеканалының алып баручылары, блогерлары).

4.3. Сайлап алу өч турда уздырыла:

**- Беренче тур (читтән торып үткәрелә)**, 2021 елның 01 февраленнән 2021 елның 30 апреленә кадәр.

Бәйгенең Беренче турында катнашу өчен Катнашучы әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килүче, балалар өчен татар телендә үзе иҗат иткән музыкаль әсәр (текст белән) белән бергә гариза җибәрә (татар классикларының әдәби әсәрләрен куллану да рөхсәт ителә), (алга таба - Җыр). Гаризаны Оештыручының shayanmuzik@mail.ru электрон почтасы адресына, яисә флешкага яздырып Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 15 йорт адресы буенча китереп бирергә дә ярый, әмма килер алдыннан килү вакытын «ШАЯН ТВ» телеканалы администраторына 570-50-29 телефон номеры аша шалтыратып әйтергә кирәк була.

1) Беренче тур кысаларында Жюри (аноним рәвештә) читтән торып гаризаларны карый һәм сайлап алуны уздыра;
2) Беренче тур нәтиҗәләре буенча Жюри тәкъдим ителгән гаризалардан 20 катнашучыны сайлап ала, алар икенче этапка үтә;
3) Беренче тур нәтиҗәләре «ШАЯН ТВ» телеканалының shayantv.ru сайтында игълан ителәчәк.

**- Икенче тур (читтән торып үткәрелә)**:

- 2021 елның 11 маеннан 17 маена кадәр https://shayantv.ru сайтында интернет аша тавыш бирү юлы белән үткәрелә. Жюри карары буенча, беренче тур җиңүчеләре арасыннан 10 катнашучы өченче турда катнашу өчен сайлап алына.

**- Өченче тур (читтән торып үткәрелә)**:

- 2021 елның 20 маеннан 2021 елның 25 маена кадәр, икенче тур нәтиҗәләре буенча, Жюри (аноним рәвештә) читтән торып 5 Катнашучыны сайлап ала, алар Бәйгенең җиңүчесе дип табыла.

Бәйге нәтиҗәләре «ШАЯН ТВ» телеканалының shayantv.ru. сайтында игълан ителәчәк.

4.4. Жюри чыгарган нәтиҗәләр соңгы һәм үзгәртелми.

4.5. Нигезләмәдә даталар якынча язылган, Оештыручының карары буенча алар үзгәрергә мөмкин. Үзгәрешләр турында «ШАЯН ТВ» телеканалының рәсми сайтыннан (shayantv.ru) белергә мөмкин булачак.

4.6. Бәйге нәтиҗәсе буенча һәр җиңүчегә:

- Музыкаль әсәр профессиональ студиядә яздырылачак (фонограмма), Музыкаль әсәргә аранжировка эшләнәчәк (оркестр аккомпанементы булуы да мөмкин), Җырга клип төшереләчәк;
- 115 000 (Йөз унбиш мең) сум күләмендә акчалата премия бирү каралган, һәр Катнашучыдан 13% ФЗКС (НДФЛ) тотыла, композиторга һәм шагыйрьгә 57 500әр сум (Илле җиде мең биш йөз сум) бирү каралган.

Жюри карары буенча Бәйге җиңүчеләренә Җырны «ШАЯН ТВ» телеканалының «Сәйлән» балалар телевизион татар җыр фестивалендә башкару мөмкинлеге бирелә.

4.7. Җиңүчеләргә акчалата премия алар җибәргән банк реквизитларына күчерелә (аерым композиторга һәм аерым шагыйрьгә / яисә хокук иясенә). Физик затлар кеременнән салым, салым агенты тарафыннан 13% күләмендә алына, түләү чыганагы – «Яңа Гасыр «ТРК»АҖ.

## 5. БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫ ЭШЛӘРГӘ ҺӘМ ГАРИЗАЛАРГА ТАЛӘПЛӘР.

5.1. Катнашучының гаризасында Җырның тере тавышка башкарылган аудиоязмасы яисә аерым файлларның партитурасы булырга тиеш. Гариза әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән 1 нче Кушымта формасы буенча тапшырыла.

Җырны әзер килеш башкарылган формада яки әзер аранжировка белән җибәрергә була.

Җыр балалар аудиториясенә туры килергә тиеш.

5.2. Әсәрнең яңгырашы аһәңлерәк булсын өчен синтезатор, электрогитара һ.б. акустик уен кораллары куллану рөхсәт ителә.

5.3. Вокализация эффектлары кертү / яисә текстны партитурада куллану рөхсәт ителә.

5.4. Татар классиклары әсәрләрен куллану рөхсәт ителә.

5.5. Бер Җырның озынлыгы: минут ярымнан кимрәк һәм 4 минуттан күбрәк булмаска тиеш.

5.6. Бәйгедә катнашу өчен оригинал көйле, моңа кадәр киң җәмәгатьчелек алдында башкарылмаган, басылып чыкмаган, тиражлы чыганакларга яздырылмаган Җырларны гына катнаштыру рөхсәт ителә. Бәйгедә нинди дә булса башка бәйгеләрдә катнашкан Җыр белән катнашу рөхсәт ителми. “Балачак жыры” бәйгесенең үткән елгы җиңүчеләре дә бәйгедә катнаша алмый.

5.7. Бәйгене Оештыручы (оештыру комитеты) биредәге Нигезләмәгә туры килмәү очракларын ачыкласа, теләсә кайсы этапта гаризаны кире кагарга хокуклы.

5.8. Бәйгедә катнашучы 3 турга үткәч, автор, Килешү төзеп, Җырга булган махсус хокукларны тулысынча Оештыручыга тапшыра (әлеге Нигезләмәнең 2нче номерлы Кушымтасы). Катнашучының Җырны алга таба куллануы Оештыручы белән сөйләшеп, килешкәннән соң гына рөхсәт ителә.

5.9. Катнашучы Җырга булган барлык хокукларның, шул исәптән башкарганда да (башкарылган очракта) үзендә булуын гарантияли. Музыкаль әсәр кемнең дә булса башкарылуында тәкъдим ителгән очракта, Оештыручы башкаручыны алмаштыру хокукына ия була.

## 6. БӘЙГЕНЕҢ ЖЮРИ СОСТАВЫ ҺӘМ ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ САЙЛАП АЛУ ТӘРТИБЕ.

6.1. Жюри гаризаларны карый һәм Бәйгенең җиңүчеләрен билгели.

6.2. Җиңүчеләрне билгеләү критерийләре:

- текст әдәби татар телендә язылырга тиеш, мөрәҗәгатьләр, диалоглар кертү рөхсәт ителә;
- балалар аудиториясе кызыксынуларына туры килергә тиеш;
- татар көе булырга тиеш;
- һәм башкалар.

6.3. Жюри әгъзаларының һәркайсына (аноним рәвештә) оештыру комитеты тарафыннан Бәйгедә катнашырга рөхсәт ителгән әсәрләрнең тулы пакеты таратыла.

## 7. БАШКА ШАРТЛАР

7.1. Бәйгене Оештыручы яки аның дәвамчылары Җырны башкару белән бәйле рәвештә нинди дә булса юридик яки физик затларга, шулай ук авторлык һәм чиктәш хокуклар белән күмәк идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга түләү җаваплылыгыннан азат ителә.

7.2. Бәйге турында тулы мәгълүмат «ШАЯН ТВ» телеканалының барлык интернет ресурсларында: https://shayantv.ru/ сайтында, Инстаграм социаль челтәрендәге @shaiantv аккаунтында, Вконтакте социаль челтәрендәге https://vk.com/shayantv төркемендә, https://youtube.com/ШАЯНТВ/ YouTube каналында урнаштырылачак.

7.3.Бәйгедә катнашу өчен гаризалар shayanmuzik@mail.ru электрон почтасына, “балалар җыры бәйгесенә” тамгасы белән җибәрелә (әлеге Нигезләмәнең 1 нче Кушымтасындагы форма буенча).

Өстәмә мәгълүмат 8(843) 570-50-29, 570-50-33 телефон номеры һәм shayanadmin@tnvtv.ru электрон почтасы буенча.

*Татар телендә балалар өчен җыр иҗат итүчеләрнең*
*“Балачак җыры” («Песня детства») II бәйгесен*
*үткәрү турындагы*
**Нигезләмәнең 1 нче номерлы Кушымтасы**

**Катнашучының анкетасы №1**

| | |
|---|---|
| Композиторның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, кыскача тәрҗемәи хәле (биографиясе), документлары (паспорт, ИНН, СНИЛС), элемтә өчен телефон номеры | |
| Шагыйрьның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, кыскача тәрҗемәи хәле (биографиясе), документлары (паспорт, ИНН, СНИЛС), элемтә өчен телефон номеры | |
| Белеме (уку йорты, тәмамлаган елы), эш яки уку урыны. Композиторлар иҗади союзында әгъза булу-булмавы турында мәгълүмат | |
| Белеме (уку йорты, тәмамлаган елы), эш яки уку урыны. Шагыйрьләр иҗади союзында әгъза булу-булмавы турында мәгълүмат | |

Катнашучының имзасы:______________________________/______________________________/
*ФИО*

Катнашучының имзасы:______________________________/______________________________/
*ФИО*

**Әсәрнең анкетасы №2**

| | |
|---|---|
| Партитураның PDF-файлы | |
| Әсәрнең тексты | |
| Әсәр башкарылган аудиоязма | |

Катнашучының имзасы:______________________________/______________________________/
*ФИО*

Катнашучының имзасы:______________________________/______________________________/
*ФИО*

Татар телендә балалар җыры язучыларның
“Балачак җыры” («Песня детства») II
бәйгесен үткәрү турындагы
**Нигезләмәнең 2 нче номерлы Кушымтасы**

**Махсус хокукларны тапшыру турында**
**Килешү**

Казан ш. «___»_________20__ ел

______________________, алга таба «Авторлык хокуклары иясе», бер яктан
(ФИО)
һәм «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе акционерлык җәмгыяте, алга таба «Хокук алучы», вәкаләтле вәкиле - Генераль директорның беренче урынбасары И.И. Сафиуллин, 01.01.2021 елдагы 1 нче номерлы Ышанычнамә буенча эш итүче, икенче яктан, бергәләшеп алар «Яклар», әлеге Килшеүне түбәндәгеләр турында (текстта алга таба – «Килешү») төзеделәр:

1. КИЛЕШҮНЕҢ ПРЕДМЕТЫ.

1.1. Авторлык хокуклары иясе Хокук алучыга интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенә булган махсус хокукларны Килешүдә күрсәтелгән Кушымта нигезендә музыкаль әсәрне текст белән бергә тулысынча тапшыра.

1.2.Махсус хокукларның күчү вакыты булып кабул итү Актына кул куйган көн санала (Килешүдәге Кушымта).

2. ГАРАНТИЯЛӘР.

2.1. Авторлык хокуклары иясе гарантия бирә:

- интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенә үзенең чыннан да махсус хокуклары булуына;

- интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенең оригинал булуына, һәм аның авторлык, арадаш һәм өченче затларның закон тарафыннан саклана торган хокукларын бозмавына. Хокук алучыга өченче затлар тарафыннан, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенә яисә анда кулланылучы объектларга (өлешләргә) авторлык һәм арадаш хокукка ия булучылар, индивидуализация чараларына хокукы булучылар, исем һәм сурәткә, шәхси яки гаилә серләренә хокукы булучылар тарафыннан таләпләр, претензия, дәгъвалар белдергән очракта, Авторлык хокукына ия булучы аларны үз көче һәм үз чыгымына хәл итәргә бурычлы;

- әлеге килешүне төзегән датага, Хокук алучыга тапшырылучы хокукның әлеге килешү нигезендә, өченче затларга тапшырылмавына;

- әлеге Килешүгә беркетелгән Кушымталардагы мәгълүматларның ышанычлы булуына, Хокук алучы тарафыннан яңадан тикшерүне таләп итәргә кирәк булмавына.

2.2. Авторлык хокукына ия булучы бүләк барабәренә Хокук алучыга Россия Федерациясе һәм дөньяның төрле илләрендәге законнар нигезендә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенә булган барлык хокукларын төрлечә куллана алу мөмкинлеген тапшыра.

2.3. Хокук алучы гарантия бирә:

- интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсен яисә аның кайсы да булса өлешен кулланганда Хокук алучы интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе авторын күрсәтергә. Шуның белән бергә, әгәр интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе авторының исемен күрсәтү

мөмкинлеге булмаса (мәсәлән, радиотрансляцияләрдә, берәр фрагментын кулланганда һ.б.ш.), интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе авторының исемен күрсәтмәү авторның шәхси милек булмаган хокукын бозмый дип санала.

2.4. Киләчәктә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсен төрле объектив формаларда үзгәртеп тудырылган әсәрләрне куллану буенча барлык хокуклар Хокук алучыга бирелә. Киләчәктә Авторлык хокукы иясе һәм башка өченче затлар Хокук алучы тудырган объектларга нинди дә булса, шул исәптән аларны кулланган өчен түләү каралган очракта да, дәгъва кыла алмый.

2.5. Хокук алучы яки аның дәвамчылары интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсен куллану белән бәйле рәвештә нинди дә булса юридик яки физик затларга, шулай ук авторлык һәм чиктәш хокуклар белән күмәк идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга түләү җаваплылыгыннан азат ителә.

## 3.БҮЛӘКЛӘҮ.

3.1. Әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган махсус хокукның бәясе 100 (йөз) сум 00 тиен.

3.2. Авторлык хокукы иясе махсус хокукларны Хокук алучыга түләүсез нигездә тапшырырга ризалаша.

3.3. Югарыда күрсәтелгән сумма Хокук алучы түләргә тиешле бердәнбер сумма, ә Авторлык хокукына ия булучы кабул итү актына кул куйганда әлеге Килешү нигезендә махсус хокукны тапшырганы өчен ул сумманы кабул итеп ала.

## 4. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛДӘН ЧЫГАРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Әлеге Килешү ике Як кул куйганнан соң гамәлгә керә, Якларның һәрберсенең үз бурычларын үтәгәнче гамәлдә була.

4.2. Әлеге Килешү Якларның сөйләшеп килешүе нәтиҗәсендә гамәлдән чыга ала. Килешүне гамәлдән чыгарырга теләүче Як әлеге теләген икенче Якка әлеге Килешүне гамәлдән чыгарырга теләгән көннән, 30 календарь көнннән дә соңга калмыйча белдерергә тиеш.

## 5. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ.

5.1. Үз бурычын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән Як килешү буенча, РФ законнары нигезендә җавап тота.

5.2. Әгәр Яклар уйланмаган яки булдыра алмый торган сәбәпләр аркасында өлешчә яисә тулысынча бурычны үти алмаса, җаваплылыктан азат ителә. Хәл итә алмастай шартлар турында мондый хәл билгеле булганнан соң 5 (биш) көн эчендә, бер-берсенә язма рәвештә хәбәр бирергә тиешләр.

Хәл итә алмаслык шартның булуы вәкаләтле органнар яисә оешмалар тарафыннан расланырга тиеш.

## 6. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘРЕ

6.1. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде һәм Яклар тарафыннан кул куелды, Якларга берәр нөсхә бирелде.

6.2. Һәр кушымта, актлар, әлеге Килешүгә өстәмәләр һәм үзгәрешләр язмача бирелә, Якларның вәкаләт бирүче вәкилләре тарафыннан кул куела, һәм әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.3. Әлеге Килешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән теләсә кайсы бәхәс, фикер каршылыгы яисә дәгъва, яисә аны бозу, туктату һәм гамәлдән чыгару Яклар тарафыннан судка кадәр сөйләшүләр алып бару тәртибендә хәл ителә.

6.4. Фикер каршылыгы судка кадәр хәл ителмәсә, ул суд тәртибе буенча хәл ителәчәк.

7. РЕКВИЗИТЛАР ҺӘМ ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

АВТОР ХОКУКЫНА ИЯ БУЛУЧЫ:

.

______________/______________/
(ФИО)

ХОКУК АЛУЧЫ:

«Яңа гасыр» ТРК» АҖ
420095, Казан ш., Ш. Усманов ур, 9
ИНН/КПП 1653021456/165801001
р/с № 40702810800090007556
ҖЧО «Аверс» Банкында
к/с 30101810500000000774
БИК:049205774
тел: (843) 554-30-33, 570-51-00

______________/И.И. Сафиуллин/

Генераль директорның
Беренче урынбасары

К Договору № ____________ от___________ 20__ г.

Акт приема – передачи

г. Казань «___» ___________20___г.

_________________________________________, именуемый в дальнейшем «Правообладатель», с одной стороны и Акционерное общество «Телерадиокомпания «Новый Век», именуемое в дальнейшем «Приобретатель», в лице Первого Заместителя Генерального директора И.И. Сафиуллина, действующего на основании Доверенности № 1 от 01.01.20__ г., с другой стороны, и, совместно именуемые «Стороны», подписали настоящее приложение о нижеследующем:

1. Правообладатель предоставил, а Приобретатель принял в полном объеме исключительные права на следующее музыкальное произведение с текстом:

| № | Вид музыкального произведения с текстом | Наименование | Хронометраж | Автор текста | Композитор |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

ПРАВООБЛАДАТЕЛЬ: ПРИОБРЕТАТЕЛЬ:

___________________/_______________/ _______________/ _________________/